**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
**IV чакырылыш**
423740, Актаныш авылы, Ленин пр., 17нче йорт. Тел. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**IV созыва**
423740, село Актаныш, пр. Ленина, дом 17. Тел/. 3-44-44, факс 3-44-38.

**РЕШЕНИЕ** — **КАРАР**

15.09.2018 — № 30-07

**«Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» Актаныш муниципаль районы Советының 2017 елның 04 декабрендәге 22-02 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы үзгәрешләренә бәйле рәвештә, «Актаныш» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Актаныш муниципаль районы Советының 2017 елның 04 декабрендәге 22-02 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районында муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктта «җирле үзидарә органы җитәкчесе» сүзләреннән соң «муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе рәисе яисә вазыйфаларны башкарырга вәкаләтле башка зат» сүзләрен өстәргә.
яллаучы (эш бирүче) вәкиле.»;

2) **3 пунктның 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**
«Россия Федерациясе дәүләт телен белгән гражданнарның муниципаль хезмәткә тигез керүе һәм аның җенесенә, расасына, милләтенә, чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи хәленә, яшәү урынына, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, иҗтимагый берләшмәләргә каравына, шулай ук муниципаль хезмәткәрнең һөнәри һәм эшлекле сыйфатларына бәйле булмаган башка шартларга тигез булуы;»;

3) **3 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:**
«- муниципаль хезмәтнең тотрыклылыгы;
- муниципаль хезмәткәрләр эшчәнлеге турында мәгълүматтан файдалану мөмкинлеге;
- иҗтимагый берләшмәләр һәм гражданнар белән үзара хезмәттәшлек.»;

Актаныш муниципаль районы Башлыгы — Э.Н.Фәттахов